**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Ютазы районы Ютазы авыл җирлегенең Керкәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**«22» ноябрь 2023 ел** **№1**

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә 2023 елның 21 ноябрендә «2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге территориясендә урнашкан Керкәле торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I һәм II төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Украинада махсус хәрби операциядә катнашучылардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- Кәркәле торак пунктында зират территориясен коймалауны ремонтлау(төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү)

- Керкәле торак пунктында торак пункт эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү) - соравы буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә ярашлы рәвештә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 24 катнашучысы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 14 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 14 катнашучы тавыш бирде;

"КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены түбәндәгеләрне хәл итте:

1. Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлегенең Керкәле торак пунктында гражданнар җыенын узган һәм гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. «2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге территориясендә урнашкан Керкәле торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I һәм II төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Украинада махсус хәрби операциядә катнашучылардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- Кәркәле торак пунктында зират территориясен коймалауны ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү)

- Керкәле торак пунктында торак пункт эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү) - соравын кабул ителгән дип санарга.

3. Ютазы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итү, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында (http://jutaza.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге башлыгы Л.М.Хәйруллина